**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Фома авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**1 февраль 2021 ел** **№ 13**

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авылы» муниципаль берәмлеге территориясендә индивидуаль торак төзелеше, блокланган торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәрен билгеләү турында**

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 07 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясы нигезендә гражданнарның индивидуаль торак төзелеше, блокланган торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлекләрен бертигез сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге советы, **КАРАР ИТТЕ:**

1. Гражданнарга милек итеп бирелә торган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авылы» муниципаль берәмлеге милкендәге дәүләт милке чикләнмәгән яисә муниципаль берәмлек милкендәге җир кишәрлекләренең иң чик минималь күләмнәрен түбәндәгечә билгеләргә:

1.1. торак пунктлар чикләрендә шәхси торак төзелеше өчен – 1 000 кв. м.;

1.2. блокланган торак төзелеше өчен – 1 000 кв. м.;

1.3. шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен – 1 000 кв. м.

2. Гражданнарга милеккә бирелә торган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авылы» муниципаль берәмлеге милкендәге яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренең максималь чик күләмнәрен түбәндәгечә билгеләргә:

2.1. торак пунктлар чикләрендә шәхси торак төзелеше өчен – 1 500 кв. м.;

2.2. блокланган торак төзелеше өчен – 1 500 кв. м.;

2.3. шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен – 5 000 кв. м.

3. Гражданнардан фактта файдаланудагы яисә әлеге карар үз көченә кергәнче законда билгеләнгән тәртиптә бирелгән төзелә торган җир кишәрлегенең күләме иң чик минималь күләмнәрдән кимрәк булган йә әлеге карар белән каралган иң чик максималь күләмнәрдән артыграк булган очракларда, бу җир кишәрлеге өчен аның зурлыгы тиешенчә минималь яисә максималь чик күләмнәрдә була.

4. Гражданнарның даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану яисә гомерлек мирас итеп биләү хокукындагы җир кишәрлекләренә җир кишәрлекләренең чик

Әлеге карарның 3 пункты нигезендә бирелә торган җир кишәрлекләре мәйданын тәгаенләштергәндә аерма 10% тан артмаска мөмкин.

6. Чикле зурлыкка карата максималь күләмнәрдән артыграк булган җир кишәрлекләре, нормадан артып киткән кишәрлекнең бер өлеше мөстәкыйль җир кишәрлеге буларак бүленә алмаганда һәм кызыксынган катнаш җирдән файдаланучыларны килештергән очракта, искәрмә булып тора.

7. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авылы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарга шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм индивидуаль торак төзелеше өчен милек буларак бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәрен билгеләү турында» 2016 елның 15 мартындагы 23 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http://nurlat.tatarstan.ru/.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы<br>
Нурлат муниципаль районы<br>
Фома авыл җирлеге<br>
Советы рәисе Р.Х. Абдрахманов